Февраль, 2025 нче ел

# ЧИШМӘ БАШЫ

**“АРЧА 1 НЧЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ”**

## *23 нче февраль—*
## *ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР КӨНЕ*




**Бүгенге бәхет мәңгегә**
**Кояштай балкып**
**торсын.**
**Ил тынычлыгын**
**саклаучы**
**Солдатлар исән**
**булсын!**

Ватанны саклаучылар коне – батырлык, намус һәм кыюлык көне белән ихластан котлыйбыз сезне. Бүгенге бәйрәм көчле рухлылык, ир-егетләрнең кыюлык, намус һәм абруй шикелле сыйфатларга ия булуларын тагын бер кат раслый торган тантана.

Туган илгә һәм үз халкыңа хезмәт итү ул, туган илен чын күңелдән сөюче гражданнарның һәрчак иң югары максаты булды һәм шулай ук булып калса иде.

Сезгә һәм якыннарыгызга тыныч күк йөзе, ныклы сәламәтлек, бәхет-шатлык, рухи һәм матди байлык, һәр эшегездә бары тик уңышлар гына телибез. Мөбәрак булсын бүгенге матур бәйрәмегез!!!

# 21 нче февраль — Халыкара туган тел көне

Туган тел һәркем өчен дә газиз сүз. Чөнки иң кадерле, бернәрсә белән дә алыштырылмый торган “әни”, “әти”, “әби”, “бабай” сүзләрен башлап туган телдә әйтәбез. Туган үскән ил- җирнең якынлыгын Ватанның газизлеген без туган тел ярдәмендә тойганбыз. Шагыйрьләребезнең матур-матур шигырьләрен ятлап, әле дә куанабыз, рухланабыз.

Шул уңайдан бакчабызда "Туган телем-Тукай теле" дип исемләнгән бәйрәм булып үтте. Икенче зурлар төркемендә тәрбияләнүче балалар туган телдә шигырьләр сөйләделәр, җырлар җырладылар, халкыбызның күркәм уеннарын уйнадылар.

Безнең телебез – татар теле. Бакчабызга йөрүче һәр бала бүген горурланып "Туган тел" җырын җырлады.

Хөрмәтле милләттәшләр, кадерле дуслар! Барыгызны да халыкара туган тел көне белән котлыйбыз. Татар халык мәкале: “Туган телне кадерләгән халык кадерле булыр”, – ди. Туган телләребезне саклыйк, яклыйк,чөнки милләтнең яшәешендә





Бакчабызда Халыкара туган тел көне уңаеннан, "Туган телем - иркә гөлем" дип исемләнгән шигырь сөйләүчеләр бәйгесе үткәрелде. Әлеге конкурста бакчабызда тәрбияләнүче төрле яшьтәге нәниләр катнашты. Балалар татар язучылары Г.Тукай, Р.Корбан, Ш.Маннур, Р. Вәлиева шигырьләрен татар телендә сәнгатьле итеп башкарды. Аларның чыгышын жюри әгъзалары бик игътибар белән тыңлаганнан соң, балаларның сөйләү үзенчәлекләрен, үз-үзләрен сәхнәдә тоту алымнарын исәпкә алып, урыннар билгеләде.

Яшь үзенчәлекләренә туры китереп, I, II, III урыннарны яулаган һәм конкурста актив катнашкан балаларга грамоталар тапшырылды. Туган телебез сагында торучы балаларыбызга алда тагын да зур уңышлар телибез!



# Әтиемнең көчле куллары






Бакчабызда 23 нче февраль - Ватанны саклаучылар көне уңаеннан бәйрәм чаралары булып узды. Ватанны саклаучылар көне балаларда патриотизм, сугышчыларга хөрмәт, Ватаныбызның иң яхшы традицияләренә карата бер-береңне хөрмәт итү хисе тәрбияли. Менә бүген дә балалар этиләренә бик матур бәйрәм әзерләделәр. Бәйрәм патриотик тәрбияви җырлар, биюләр белән үрелеп барды, беркем дә читтә калмады.Алга таба балалар этиләре белән бергә бәйрәмдә үз көчләрен, җитезлекләрен һәм зирәклекләрен күрсәттеләр, күңелле конкурсларда катнаштылар.
Күкләребез аяз, илебез тыныч булсын!

## 15 нче февраль—
## Советлар Союзы Герое—Муса Җәлилнең туган көне

Бакчабызда бөек шагыйрь Муса Җәлилнең туган көненә багышланган "Без-Җәлил оныклары" дигән әдәби чара узды. Әлеге чараның максаты балаларны шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты һәм сугышта күрсәткән батырлыклары, Җәлилчеләр белән таныштыру, алар белән горурлану хисләре тәрбияләү иде. Балалар бөек шагыйрьнең тормыш юлы турында презентация карадылар, шигырьләр сөйләделәр, "Кызыл ромашка" шигыренә театральлләштерелгән күренеш күрсәттеләр. Хәзерге вакытта Ватаныбызның патриот гражданинын тәрбияләү бик мөһим. Безнең балалар үз геройларын – үз тормышларын геройларча бирүчеләрне, батырлык һәм каһарманлык күрсәтергә омтылучыларны белергә тиеш!




***Газетаны оештыручы мөхәррир***: *татар теле тәрбиячесе—Камалиева Гөлназ Рәис кызы*